КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 19 март г.Казань № б-482

Җәмәгатьчелекнең хезмәтне саклау мәсьәләләренә карата игътибарын җәлеп итү, җитештерүдә бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны булдырмау, шулай ук эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә хезмәт культурасын үстерү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 1 апреленнән 1 июненә кадәр Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чаралар үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чараларны, шул исәптән, эш бирүчеләрне һәм хезмәткәрләрне җәлеп итеп, хезмәткәрләргә эшләр башкаруның куркынычсыз алымнарын өйрәтүне оештыру, хезмәтне саклау өлкәсендә бозуларны профилактикалау һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәү мәсьәләләре буенча форумнар, Хезмәтне саклау көннәрен, «түгәрәк өстәл» утырышларын, киңәшмәләр, смотр-конкурслар үткәрү чараларын тормышка ашыруда актив катнашырга, шулай ук Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә – актив катнашуны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына бу боерыкның 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны 2021 елга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән тиешле баш эш итүчеләр буенча күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә тормышка ашыруны гамәлгә ашырырга.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны оештырырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин